# ЗАКОН
## РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в статью 2 Закона Республики Татарстан «О налоге на имущество организаций»**

Принят<br>Государственным Советом<br>Республики Татарстан<br>16 февраля 2017 года

**Статья 1**

Внести в статью 2 Закона Республики Татарстан от 28 ноября 2003 года № 49-ЗРТ «О налоге на имущество организаций» (в редакции Закона Республики Татарстан от 5 июля 2010 года № 51-ЗРТ) (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2003, № 11; 2010, № 7 (II часть); 2011, № 5, № 8 (I часть); 2012, № 2, № 6 (I часть); 2013, № 3, № 6 (II часть), № 10, № 12 (I часть); 2014, № 10 (I часть); 2015, № 6 (I часть), № 8 – 9; 2016, № 1 – 2, № 6 (III часть); Собрание законодательства Республики Татарстан, 2016, № 44 (I часть); 2017, № 1 (I часть) следующие изменения:

1) в части 2 слова «железнодорожных путей общего пользования,» исключить;

2) дополнить частью $2^1$ следующего содержания:

«$2^1$. В отношении железнодорожных путей общего пользования и сооружений, являющихся их неотъемлемой технологической частью, налоговые ставки устанавливаются в 2017 году в размере 1 процента, в 2018 году – 1,3 процента, в 2019 году – 1,3 процента, в 2020 году – 1,6 процента.».

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу со дня его официального опубликования и распространяется на правоотношения, возникшие с 1 января 2017 года.

Президент<br>Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль<br>22 февраля 2017 года<br>№ 5-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Оешмалар мөлкәтенә салым турында”**
**Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына**
**үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2017 елның 16 февралендә
кабул ителде

**Статья 1**

“Оешмалар мөлкәтенә салым турында” 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына (2010 елның 5 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 11; 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 5, № 8 (I өлеш); 2012, № 2, № 6 (I өлеш); 2013, № 3, № 6 (II өлеш), № 10, № 12 (I өлеш); 2014, № 10 (I өлеш); 2015, № 6 (I өлеш), № 8 – 9; 2016, № 1 – 2, № 6 (III өлеш); Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2016, № 44 (I өлеш); 2017, № 1 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 өлештә “Гомуми файдаланудагы тимер юлларга,” сүзләрен төшереп калдырырга;

2) түбәндәге эчтәлекле $2^1$ өлеш өстәргә:
“$2^1$. Гомуми файдаланудагы тимер юлларга һәм аларның аерылгысыз технологик өлеше булып торган корылмаларга карата салым ставкалары 2017 елда – 1 процент, 2018 елда – 1,3 процент, 2019 елда – 1,3 процент, 2020 елда 1,6 процент күләмендә билгеләнә.”.

**Статья 2**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2017 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2017 ел, 22 февраль
№ 5-ТРЗ